**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«16» декабрь 2014 ел № 34/6

**Халык дружинасы төзелергә мөмкин булган территория чикләрен билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 өлеше 37 пункты, «Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы 2 пункты, «Иҗтимагый тәртипне саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары арасында ирекле халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында» 2014 елның 8 декабрендәге килешүләр нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2007 елның 31 гыйнварындагы 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән Тукай муниципаль районы муниципаль берәмлеге чикләре нигезендә халык дружинасы төзелергә мөмкин булган территориянең чикләрен билгеләргә.
2. Әлеге карар үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызылыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе В.Г. Хаҗиев